ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.03.2025 Балык Бистәсе штп. № 49пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 02.12.2020 №255пи карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.12.2024 № 2972-р һәм 14.02.2025 № 307–р Күрсәтмәләренә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 декабрендәге 255пи номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 16.03.2021 ел, №49пи, 01.04.2021 №59пи, 23.06.2021 №135пи, 12.11.2021 №242пи, 25.04.2022 №83пи,13.03.2023 №72пи, 29.02.2024 №45пи, от 29.03.2024 №78пи, 30.07.2024 №204пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.) Программаның Паспортында "Программаны финанслау чыганаклары” пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Программаны финанслау чыганаклары</td>
<td>Җирле бюджет (агымдагы финанслау), республика бюджеты акчасы.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме 14620,13 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет средстволары хисабына-5554,64 мең сум (мең сум)
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Балык Бистәсе муниципаль районының җирле бюджеты средстволары (ҖБ)</th></tr>
<tr><td>2021</td><td>1069,38</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1054,68</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1096,49</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1142,81</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>1191,28</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>5554,64</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td>
</tr>
</table>

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**« III. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ**

Программаны тормышка ашыру өчен, мөмкинлекләрдән чыгып, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчалары җәлеп ителә, шулай ук авыл һәм шәһәр җирлекләре һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акча җәлеп итү күздә тотыла.

Программаны финанслауның гомуми күләме 14620,13 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет средстволары 5554,64 мең сум.

(мең. сум)

| Ел | Балык Бистәсе муниципаль районының җирле бюджеты средстволары (ҖБ) |
|---|---|
| 2021 | 1069,38 |
| 2022 | 1054,68 |
| 2023 | 1096,49 |
| 2024 | 1142,81 |
| 2025 | 1191,28 |
| Барлыгы: | 5554,64 |

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган җирле бюджет акчаларыннан файдалану күздә тотыла.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга җирле бюджет проектын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен аныкланырга тиеш»;

1.3. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ начальнигы вазифаларын башкаручы Д.Ю. Вильчинскаяга йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.03.2025 № 49пи карары белән расланган

“2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спорты үстерү” муниципаль программасына кушымта

## "2021-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТНЫ ҮСТЕРҮ” МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРНЫ ФИНАНСЛАУ

| Максаты | Бурычлары | Чаралар исемлеге | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахырыгы нәтиҗә-ләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлеклә-ре | Индикаторларның (прогноз) әһәмияте һәм еллар финанслау, мең сум | | | | | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыру | Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спорт үсешенең норматив хокукый базасын камилләштерү | Физкультура-спорт юнәлешендәге белем бирү оешмалары (Спорт мәктәбе) эшенә спортчы паспортын кертү | 2021 – 2025 еллар | Спорт мәктәпләре саны, берәмлек | 1<br>- | 1<br>- | 1<br>- | 1<br>- | 1<br>- | ЯССТБ МКУ, “Спорт мәктәбе” МБУ |
| | | | | Спорт мәктәбендә шөгыль-ләнүче балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | 486 | 511 | 536 | 561 | 586 | ЯССТБ МКУ, “Спорт мәктәбе” МБУ |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Балык Бистәсе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ, «Дельфин «спорт-сәламәтләндерү комплексы» МБУ, спорт объектлары тренерлары арасында спорт-массакүләм һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен иң яхшы куюга район конкурсы үткәрү турындагы нигезләмәләрне эшләү, раслау һәм камилләштерү | 2021 – 2025 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ, “Спорт мәктәбе” МБУ |
| | Иҗтимагый физкультура-спорт оешмаларына ярдәм күрсәтү | Мәктәп командаларының бөтенроссия, республика спорт ярышларында катнашуына максатчан ярдәм күрсәтү. Гомуми белем бирү оешмаларында спортның уен төрләрен үстерү, | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ, БСБ(П)Ү МБУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | шул исәптән ярышлар уздыру: "КЭС-БАСКЕТ" мәктәп баскетбол лигасы»; "Мини-футбол-мәктәпкә!» Бөтенроссия проектын гамәлгә ашыру кысаларында мини - футбол буенча ярышлар»."Прези-дент ярышлары","Пре-зидент спорт уеннары" ярышларында һәм фестивалендә катнашу | | | | | | | | |
| | | Тәҗрибә һәм методик материаллар тарату максатыннан район авыл җирлекләрендә, район предприятиеләрендә һәм оешмаларында физик культура һәм спортны | 2021 - 2025 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы "Мәгариф бүлеге" МКУ |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | үстерү буенча комплекслы тикшерүләр үткәрү | | | | | | | | |
| | Физкультура-спорт эшчәнлеген финанс, матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү механизм-нарын камилләштерү | Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендәге белем бирү оешмаларын спорт инвентаре һәм җиһазлары белән тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына | | | | | | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| | | Гомуми белем бирү оешмаларының спорт өчен билгеләнгән объектларны кирәкле спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү | 2021 - 2025 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына | | | | | | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| 2. Халыкның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә булган ихтыяҗларын канәгать- | Заманча спорт-сәламәт-ләндерү комплекслары, махсус-лаштырылган спорт корылмалары | Физкультура-сәламәтләндерү объектларын төзү буенча республика программаларында катнашу | 2021-2025 еллар | Спорт корылма-лары саны-10 кешегә, берәмлек | 121 | 122 | 123 | 125 | 127 | МР БК, ЯССТБ МКУ |
| | | | | Спорт объектлары ның бердәм | 59,05 | 60,00 | 61,00 | 62,00 | 63,0 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру | төзү | | | үткәрүчән-лек сәләте, процент | | | | | | |
| | Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыруның яңа формаларын кертү | Белем бирү оешмаларында, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә һәм авыл җирлекләрендә физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру өчен программалар, укыту-методик кулланмалар һ. б. эшләү һәм гамәлгә кертү. | 2021-2025 еллар | Физик культура һәм спорт белән шөгыль-ләнүче район халкының чагыштыр-ма саны-процент | 52,1 | 52,9 | 53,0 | 53,3 | 53,9 | ЯССТБ МКУ, Авыл хуҗалыгы идарәсе (килешү буенча), районның җирлек БК (килешү буенча), ТР Балык Бистәсе муниципаль районы "Мәгариф бүлеге" МКУ, оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләре (килешү буенча) |
| | | Эчке эшләр органнарында исәптә торучы балигъ булмаганнарны спорт секцияләрендә һәм төркемнәрендә шөгыльләнүгә җәлеп итү | 2021-2025 еллар | | | | | | | ЯССТБ МКУ, "Спорт мәктәбе" МБУ, БСБ(П)Ү МБУ, "Дельфин" ССК МБУ, ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча), РФ ЭЭМ Балык Бистәсе районы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | буенча бүлеге (килешү буенча) |
| | Югары квалификация дәге физкультура һәм спорт белгечләрен әзерләүгә булышлык күрсәтү | Физик тәрбия, адаптив спорт укытучылары, шулай ук физкультура һәм спорт өлкәсендәге җитәкчеләр һәм белгечләр өчен яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү программаларында катнашу.<br>Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләр өчен ел саен үткәрелә торган республика семинар-киңәшмәләрендә катнашу | 2021-2025 еллар | | | | | | | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| | Югары класслы спортчылар өчен спорт резервын әзерләү | Район спортчыларын Россия һәм халыкара ярышларын әзерләү һәм катнашуларын | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | белән тәэмин итү | | | | | | | | МКУ, “Спорт мәктәбе” МБУ, “БСБ(П)Ү” МБУ |
| | | Татарстан Республикасы спорт мәктәпләре арасында укыту-тәрбия эшләренең иң яхшы куелышына республика смотр-конкурсында катнашу өчен район конкурсын үткәрү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ |
| | | Җәйге чорда «Спорт мәктәбе» МБУ, БСБ(П)Ү МБУ укучылары өчен укыту-тренировка җыеннары оештыру һәм үткәрү» | 2016-2020 еллар | - | - | - | - | - | - | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ , “Спорт мәктәбе” МБУ , “БСБ(П)Ү” МБУ |
| | Балык Бистәсе муниципаль районы халкының | Район халкы тарафыннан «Хезмәткә һәм оборонага әзер» | 2021-2025 еллар | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | төрле яшь төркемнәре арасында "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру | (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын тапшыру | | Бөтенроссия физкуль-тура-спорт комплексы нормативлары рын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми саныннан карата «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкульт-ура-спорт комплексы норматив-ларын үтәгән гражданнар саны; | | | | | | районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, район тестлау үзәкләре |
| 3. Массакүләм спортны популярлаштыру һәм җәмгыятьнең төрле катламнарын физик | Физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру | Популяр спорт-массакүләм чаралары («Милләтләр кроссы", "Россия чаңгы юллары","Бөек Ватан сугышында | 2021-2025 еллар | Физик культура һәм спорт белән шөгыль-ләнүче район халкының | 52,1<br><br>75,0 мең сум | 52,9<br><br>80,0 мең сум | 53,0<br><br>85,0 мең сум | 53,3<br><br>90,0 мең сум | 53,9<br><br>100,0 мең сум | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү юлы белән халыкның сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудыру | | Җиңү бәйрәменә багышланган район марафоны») уздыру юлы белән район халкының төрле төркемнәре арасында сәламәт, актив яшәү рәвешен пропагандалау | | чагыштыр-ма саны, процент | | | | | | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль- мәдәни өлкә бүлеге” МКУ |
| | | Спорт секцияләрендә һәм физкультура-сәламәтләндерү төркемнәрендә шөгыльләнүгә җәлеп итү юлы белән балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча чараларны эшләү һәм тормышка ашыру | 2021-2025 еллар | | | | | | | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ , “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль- мәдәни өлкә бүлеге” МКУ, ББЭ һәм ХЯК (килешү буенча), РФ ЭЭМ Балык Бистәсе районы |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | буенча бүлеге (килешү буенча), район җилекләре БК (килешү буенча), ТР Балык Бистәсе РОСТО (ДОСААФ) автомәктәбе (килешү буенча) |
| | | «Авыл офыклары» («Сельские горизонты») район газетасында, район сайтында, «Спорт мәктәбе "МБУ, БСБ(П)Ү МБУ сайтында,"ВКон-такте" битендәге социаль челтәрләрдә спорт төрләрен пропагандалау» | 2021-2025 еллар | | | | | | | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы "Мәгариф бүлеге" МКУ, "Спорт мәктәбе" МБУ, "БСБ(П)Ү" МБУ, "Авыл офыклары" газетасы редакциясе (килешү буенча) |
| | | Районның мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларының физик тәрбия укытучылары өчен | 2021-2025 еллар | | | | | | | ҮРБ (килешү буенча), ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | балаларга, яшүсмерләргә һәм яшьләргә физик тәрбия бирүне медицина тикшерүе мәсьәләләре буенча семинарлар үткәрү | | | | | | | | районы “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| | Яшәү урыны, уку, хезмәт эшчәнлеге буенча төрле категориядәге халыкның физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлы шартлар формалаштыру | Хезмәт коллективларында массакүләм- спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен яхшыртуга юнәлдерелгән комплекслы чараларны эшләү һәм тормышка ашыру.<br>Район оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында җәйге һәм кышкы спорт төрләре буенча район спартакиадалары һәм ярышлары уздыру | 2021-2025 еллар | | 450,0 мең сум | 460,0 мең сум | 470,0 мең сум | 480,0 мең сум | 490,0 мең сум | ЯССТБ МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча), район оешма, предприятие, учреждение җитәкчеләре (килешү буенча) |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә комплекслы профилактик медицина тикшерүләре уздыру | 2021-2025 еллар | | | | | | | МР БК, ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, ҮРБ (килешү буенча) |
| | | Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында картинг, милли, хәрби-гамәли, суднолар моделе һәм авиамодель спорты буенча республика физкультура-сәламәтләндерү, комплексы һәм Бөтенроссия спорт | 2021-2025 еллар | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче укучылар һәм студентларның барлык укучылар һәм студентлар-га карата чагыштыр-ма саны, процентлар | 88,8<br><br>210,0 мең сум | 88,9<br><br>220,0 мең сум | 89,2<br><br>230,0 мең сум | 89,6<br><br>240,0 мең сум | 90,1<br><br>250,0 мең сум | МР БК, ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чараларында катнашу һәм уздыру | | | | | | | | |
| | | "Күн туп", “Алтын алка" Бөтенроссия ярышларының район, зона этапларын үткәрү һәм аларда катнашу | 2021-2025 еллар | | 45,0 мең сум | 50,0 мең сум | 55,0 мең сум | 60,0 мең сум | 65,0 мең сум | ЯССТБ МКУ, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Спорт мәктәбе” МБУ, БСБ(П)Ү МБУ |
| | | Балык Бистәсе районы территориясендә халыкның урта һәм өлкән яшь төркемнәре (ветераннар, өлкән яшьтәгеләр арасында)«Өченче яшь» Спартакиадасы кысаларында район, зона һәм республика физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы, спорт чараларында | 2021-2025 еллар | | 35,0 мең сум | 45,0 мең сум | 55,0 мең сум | 60,0 мең сум | 65,0 мең сум | ЯССТБ МКУ, “Дельфин” ССК МБУ , “Сәламәт бул” клубы ( килешү буенча), “Район пенсионерлар союзы” җирле бүлеге (килешү буенча) |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | катнашу һәм үткәрү | | | | | | | | |
| | | "Сәламәтлек " спартакиадасы кысаларында авыл районнары командалары арасында чемпионатлар, беренчелекләр, ачык турнирлар, комплекслы чаралар уздыру | 2021-2025 еллар | | 180,0 мең сум | 190,0 мең сум | 200,0 мең сум | 210,0 мең сум | 220,0 мең сум | ЯССТБ МКУ |
| 4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үсеш өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыру, физик культура, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндер | | | 2021 ел | Татарстан Республикасы бюджеты, мең сум<br><br>Җирле бюджет, мең сум | 7380,7<br><br>73,807 | - | - | - | - | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге, Балык Бистәсе муниципаль районы " Хоккей һәм тимераякта |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| үү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан ясалма бозлы ябык шугалакны оператив идарә итү хокукында беркетүгә бәйле рәвештә муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә. | | | | | | | | | фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе» МБУ |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча хезмәтләр аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә спорт әзерлеге | | | 2024 ел | Татарстан Республикасы бюджеты, мең сум | 57,29 | - | - | 155,78 | - | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге, Балык Бистәсе муниципаль районы " Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе» МБУ |
| | | | | Җирле бюджет, мең сум | 0,572 | | | 1,56 | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| буенча муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләрнең үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итү максатларында. | | | | | | | | | |
| 6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үсеш өчен шартлар тәэмин итүгә, физик культура, массакүләм спортны үстерү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы | | | 2022 ел. | Татарстан Республикасы бюджеты, мең сум<br><br>Җирле бюджет, мең сум | - | 797,1<br><br>7,971 | - | - | - | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге, Балык Бистәсе муниципаль районы "  Спорт мәктәбе» МБУ |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең блоклы модульле чаңгы базасын оператив идарә итү хокукында беркетүгә бәйле рәвештә муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру. | | | | | | | | | |
| 7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик | | | 2024 ел | Татарстан Республика-сы бюджеты, мең сум | - | 170,11 | 148,46 | 125,85 | | Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау, инвентарь һәм экипировка сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында гамәлгә ашыру | | | 2025ел | Җирле бюджет, мең сум | | 1,701 | 1,484 | 1,258 | 128,6<br>1,286 | яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге, Балык Бистәсе муниципаль районы "  Спорт мәктәбе» МБУ, Балык Бистәсе муниципаль районы " Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе» МБУ |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. Татарстан Республикасы спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларының спорт командаларының спорт әзерлеге буенча программаларын гамәлгә ашыру һәм хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А төркемчәсе)катнашу | | | 2024 ел<br><br>2025 ел | Татарстан Республика-сы бюджеты, мең сум | | | | 49,3 | 52,3 | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге "МКУ, Балык Бистәсе муниципаль районының "Спорт мәктәбе " МБУ, Балык Бистәсе муниципаль районының "Хоккей һәм конькида фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе" МБУ |
| **Программа буенча барлыгы:** | | | | | 8507,37 мең сум | 2021,88 мең сум | 1244,95 мең сум | 1473,74 мең сум | 1372,18 мең сум | |

*Кулланылган кыскартулар исемлеге:

МР БК- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты;

ЯССТБ МКУ- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

МБ МКУ- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

СМӨБ МКУ- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

ҮРБ- “Балык Бистәсе үзәк район больницасы” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

“Спорт мәктәбе” МБУ- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе;

БСБ(П)Ү МБУ- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балаларны сәламәтләндерү-белем бирү(профильле) үзәге” өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе;

“Дельфин” ССК МБУ- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Дельфин” спорт-сәламәтләндерү комплексы” муниципаль бюджет учреждениесе;

ҖБ- җирле бюджет;

“Авыл офыклары” газетасы редакциясе- “Татмедиа” АҖ филиалы “Авыл офыклары” Балык Бистәсе муниципаль районы газетасы;

Район җирлекләре БК-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләренең башкарма комитетлары;

Авыл хуҗалыгы идарәсе- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе;

ББЭ һәм ХЯК- Балык Бистәсе муниципаль районы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;

РФ ЭЭМ Балык Бистәсе районы буенча бүлеге- Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге.